ГЛАВА
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.07.2021 Баулы шәһәре № 63

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгын микроисәпкә алуны әзерләүне һәм уздыруны оештыру турында

«Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 108-ФЗ номерлы Федераль закон, «2021 елгы авыл хуҗалыгы микроисәбен алуны оештыру турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 29 августындагы 1315 номерлы карары, Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнарының 2021 елгы авыл хуҗалыгын микроисәпкә алуын әзерләү һәм уздыру буенча Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә үзара эшчәнлеген оештыру максатларында

К А Р А Р И Т Ә М:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгын микроисәпкә алуын әзерләү һәм уздыру буенча ведомствоара комиссия төзергә.

2. Кушымта итеп бирелә торган түбәндәгеләрне расларга:

2.1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгын микроисәпкә алуны әзерләү һәм уздыру буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмәне;

2.2. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгын микроисәпкә алуны әзерләү һәм уздыру буенча ведомствоара комиссия составын.

3. 2021 елгы авыл хуҗалыгын микроисәпкә алуны әзерләү һәм уздыру комиссияләре үз вәкаләтләре нигезендә Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы (Бөгелмә шәһәре) территориаль органына 2021 елгы авыл хуҗалыгын микроисәпкә алуны әзерләү һәм уздыруда ярдәм күрсәтергә, шул исәптән:

3.1.Халык арасында 2021 елгы авыл хуҗалыгын микроисәпкә алуны әзерләүнең һәм уздыруның максатын, бурычларын, барышын яктыртуга юнәлдерелгән мәгълүмати-аңлату эшләре алып баруны оештырырга;

3.2. Халык санын алу турында федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 29 августындагы «2021 елгы авыл хуҗалыгы микроисәпкә алуны оештыру турында» 1315 номерлы карары, Татарстан Республикасының законнары һәм норматив хокукый актлары белән каралган 2021 елгы авыл хуҗалыгы микроисәпкә алуны әзерләү һәм уздыру вәкаләтләрен үтәүне тәэмин итәргә;

3.3. Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органының Казан шәһәрендәге дәүләт статистикасы бүлегенә (Бөгелмә шәһәре) билгеләнгән срокларда Баулы муниципаль районында яшәүче җирдән файдаланучылар, аларга беркетелгән җир мәйданын һәм терлекләрнең баш санын (2021 елның 1 гыйнварына актуальләштерелгән шәхси ярдәмче хуҗалыкларны исәпкә алу күрсәткечләре нигезендә) тапшырырга;

3.4. Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органының Казан шәһәрендәге дәүләт статистикасы бүлегенә (Бөгелмә шәһәре) Баулы муниципаль районы территориясендә яшәүче

Россия Федерациясе гражданнарын авыл хуҗалыгын микроисәпкә алу объектлары турында белешмәләр җыюга җәлеп итүдә, шулай ук авыл хуҗалыгы микроисәпкә алу объектлары турында белешмәләр җыючы затларны укыту һәм аларның эшләве өчен яраклы урыннар сайлауда, исәпкә алу кәгазьләрен һәм законнарда билгеләнгән авыл хуҗалыгы микроисәпкә алу документларын саклауда ярдәм күрсәтергә;

3.5. 2021 елда административ-территориаль һәм муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кормаска, шулай ук географик объектларның исемнәрен үзгәртмәскә.

4. «Татмедиа» ААҖ «Баулы-информ» филиалына массакүләм мәгълүмат чараларында авыл хуҗалыгын микроисәпкә алуның максатларын, бурычларын һәм әһәмиятен яктыртуга һәм уздыруга юнәлдерелгән мәгълүмати-аңлату эшләрен уздыруда ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм http://bavly.tatarstan.ru адресы буенча Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Баулы муниципаль районы
башлыгы вазифаларын башкаручы
Баулы муниципаль районы
башлыгы урынбасары Р.Г. Хәмидуллин

Баулы муниципаль
районы Башлыгының
2021 елның 05.07
63 номерлы карары белән
расланган

# Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгын микроисәпкә алуны әзерләү һәм уздыру буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгын микроисәпкә алуны әзерләү һәм уздыру буенча ведомствоара комиссия (алга таба - ведомствоара комиссия, авыл хуҗалыгын микроисәпкә алу) «Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 108-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2021 елгы авыл хуҗалыгын микроисәпкә алуны оештыру турында» 2020 елның 29 августындагы № 1315 карары нигезендә Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органының Казан шәһәрендәге дәүләт статистикасы бүлегенә (Бөгелмә шәһәре), шулай ук башкарма хакимиятнең федераль органнарының башка территориаль органнарына Баулы муниципаль районы территориясендә авыл хуҗалыгын микроисәпкә алуны әзерләү һәм уздыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтү максатында оештырылды.

Ведомствоара комиссия авыл хуҗалыгын микроисәпкә алуны әзерләү һәм уздыру буенча федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнары (алга таба - җирле үзидарә органнары) үзара эшчәнлеген оештыру өчен төзелгән коллегиаль орган булып тора.

Ведомствоара комиссия үз эшендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль конституциячел законнар, федераль законнар, Россия Федерациясе Президентының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары

һәм башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

## II. Ведомствоара комиссия бурычлары

Ведомствоара комиссиянең төп бурычлары түбәндәгеләр:

башкарма хакимият органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарының, җирле үзидарә органнарының авыл хуҗалыгын микроисәпкә алуны әзерләү һәм уздыру буенча килешенгән эшен (үзара хезмәттәшлеген) тәэмин итү;

авыл хуҗалыгын микроисәпкә алуны әзерләүгә һәм уздыруга бәйле мәсьәләләрне оператив хәл итү;

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы халкы арасында авыл хуҗалыгын микроисәпкә алуны уздыру турында мәгълүмати-аңлату эшләрен башкару.

Ведомствоара комиссия үзенә йөкләнгән бурычларны гамәлгә ашыру өчен түбәндәге мәсьәләләрне карый:

Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән авыл хуҗалыгын микроисәпкә алуны әзерләү, уздыру барышы турында үзара хезмәттәшлек;

авыл хуҗалыгын микроисәпкә алуны әзерләү һәм уздыру;

авыл хуҗалыгы микроисәпкә алуны уздыру эшенә төрле оешмаларны (оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә) җәлеп итү.

## III. Ведомствоара комиссиянең хокуклары

3.1. Төп бурычларны башкару өчен ведомствоара комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

үз утырышларында Федераль дәүләт статистика хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы, федераль башкарма хакимият

органнарының территориаль органнары, Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнары вәкилләренең авыл хуҗалыгын микроисәпкә алуны әзерләү һәм уздыру барышы турында чыгышын тыңларга;

билгеләнгән тәртиптә Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органыннан, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарыннан, Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнарыннан авыл хуҗалыгын микроисәпкә алуны әзерләү һәм уздыру мәсьәләләре буенча материаллар соратып алырга;

федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарына, Баулы муниципаль районының муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына авыл хуҗалыгын микроисәпкә алуны әзерләү һәм уздыру мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр җибәрергә;

ведомствоара комиссия эшенә федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнары вәкилләрен, иҗтимагый оешмалар вәкилләрен, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларын җәлеп итәргә.

## IV. Ведомствоара комиссия составы

Ведомствоара комиссия рәис, аның урынбасарлары, секретаре һәм ведомствоара комиссия әгъзаларыннан тора.

Ведомствоара комиссия составына, килешү буенча, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының җирле үзидарә органнары, оештыру-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә оешмалар, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре керә.

## V. Ведомствоара комиссиянең эш тәртибе

Ведомствоара комиссия эшчәнлеген рәис җитәкли. Ведомствоара комиссия рәисе булмаган очракта, аның функциясен ведомствоара комиссия рәисе урынбасары башкара.

Ведомствоара комиссия утырышлары кирәге чыккан саен уздырыла, ләкин ярты елга бер тапкырдан да ким түгел. Ведомствоара комиссия утырышларын тиешле чыганакларга язып аудио- һәм видеоконференцияләр режимында уздырырга мөмкин.

Ведомствоара комиссия рәисе (ул булмаганда урынбасары) сорауларны карау тәртибен билгели, ведомствоара комиссия утырышларының көн тәртибен раслый, ведомствоара комиссия составын үзгәртү турында тәкъдимнәр кертә.

Ведомствоара комиссия утырышларының көн тәртибе авыл хуҗалыгын микроисәпкә алуны уздыру эшләре планы нигезендә Татарстан Республикасы буенча Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең территориаль органы нигезендә төзелә.

Ведомствоара комиссия әгъзалары ведомствоара комиссия утырышларында шәхсән үзләре катнаша һәм ведомствоара комиссия утырышында карала торган мәсьәләләр турында фикер алышканда тигез хокукларга ия.

Ведомствоара комиссия утырышы, әгәр анда әгъзаларының ким дигәндә яртысы катнашса, хокуклы дип санала.

Ведомствоара комиссия карарлары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда рәис тавышы хәлиткеч булып тора (ул булмаганда урынбасарныкы).

Ведомствоара комиссия утырышында кабул ителә торган карарлар ведомствоара комиссия утырышының беркетмәләре рәвешендә рәсмиләштерелә. Карарларга ведомствоара комиссия рәисе (ул булмаганда, аның урынбасары) имза сала.

Ведомствоара комиссия эшен оештыру-техник яктан Федераль дәүләт статистика хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органының Казан шәһәрендәге дәүләт статистикасы бүлеге (Бөгелмә шәһәре) тарафыннан тәэмин ителә.

Баулы муниципаль
районы Башлыгының
2021 елның 05.07
63 номерлы карары белән
расланган

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә 2021 елгы авыл хуҗалыгын микроисәпкә алуны әзерләү һәм уздыру буенча ведомствоара комиссия
СОСТАВЫ

| | | |
|---|---|---|
| Гатиятуллин Рамил Хәкимулла улы | - | Баулы муниципаль районы башлыгы, комиссия рәисе; |
| Гозәеров Ильяс Исмәгыйль улы | - | Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисенең беренче урынбасары; |
| Талипов Альберт Мәгъсүм улы | - | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Баулы районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча); |
| Йосыпова Айгөл Нурислам кызы | - | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Баулы районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы секретаре, комиссия секретаре (килешү буенча); |
| | | Комиссия әгъзалары: |
| Леванова Евгения Михайловна | - | баш мөхәррир - “Татмедиа” ААҖ “Баулы-информ” филиалы җитәкчесе (килешү буенча); |
| Галимов Эмиль Исхак улы | - | Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасары; |
| Миңгалиева Эльвира Сирин кызы | - | Баулы муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм территориаль үсеш бүлеге начальнигы; |

| | | |
|---|---|---|
| Алексеева<br>Елена Михайловна | - | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Баулы районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең финанс-икътисад бүлеге башлыгы (авыл хуҗалыгы исәбен алу мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча); |
| Иванов<br>Александр Геннадьевич | - | Россия Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы Баулы районы буенча бүлеге начальнигы (килешү буенча). |

______________________